| | | |
|---|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Исполнительный комитет**<br>**Янурусовского сельского**<br>**поселения Сармановского**<br>**муниципального района** | | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Янурыс авыл җирлеге**<br>**башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.11.2022г. № 12

Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының
«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентын
раслау турында» 2022 елның 21 апрелендәге
5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе карарының 1 пунктының а пунктчасы нигезендә Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 апрелендәге 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан мөрәҗәгать итүче тарафыннан һәр запросның электрон формасын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән запросның дөрес тутырылмаган электрон формасындагы кырын ачыклаганда мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Янурыс авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ә.Мөхәмәдиева